ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.01.2026**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 118**

Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 2973 номерлы карар үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru)порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 21 гыйнварындагы
118 номерлы карары белән

**Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү).

2. Хезмәт күрсәтүне алучылар: физик затлар - үз составында үзара язылышкан яисә язылышмаган, әмма бергә яшәүче ата-аналар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) йә ата-ананың (уллыкка алучының, опекунның, попечительнең) берсе (алга таба – ата-аналар, ата йә ана), шулай ук җир кишәрлеген үзләренә милеккә бирү (тапшыру) турында гариза бирелгән көнгә өлкән балага 18 яшь тулганчы яисә 23 яшь тулганчы, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, өч яисә аннан күбрәк баласы, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, уллыкка (кызлыкка) һәм опекага алынган (үзләренә карата опека һәм попечительлек чикләнмәгән вакытта йә алар балигъ яшькә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) балалары булган күп балалы гаилә (алга таба – мөрәҗәгать итүче; өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар).

Мондый чакта күп балалы гаилә составына язылышмаган, әмма аларның кимендә өч уртак баласы булган атасы да, анасы да кертелә. Чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында каралган нигезләрдә үзләренә җир кишәрлеген бирү (тапшыру) хокукын гамәлгә ашырган гражданнар күп балалы гаилә составына кертелми.

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) яклый ала.

3. Хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүчегә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә бирелергә тиеш (алга таба - Бердәм портал).

Хезмәтне күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, Региональ порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында Хезмәт күрсәтү барышы турында статуслар һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе урнаштырыла.

## II. Хезмәт күрсәтү стандарты

Хезмәт күрсәтү атамасы

4.Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую

Хезмәт күрсәтүче органның исеме

5. Хезмәтне Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ күрсәтә.

Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче «Исәпкә кую» өчен мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре будып түбәндәгеләр тора:

1) мөрәҗәгать итүчене индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге алу хокукына ия гражданнар исемлекләренә кертү турында карар (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

2) хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (6 нчы кушымта).

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча хезмәт күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә (7 нче кушымта).

7. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Палата (яки Башкарма комитет) вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮтә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән электрон документның кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

9. Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның нөсхәсен кәгазь саклагычта Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

Хезмәт күрсәтү срогы

10. Хезмәтне күрсәтүнең максималь срогы мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, Башкарма комитетка, КФҮ мөрәҗәгать иткәндә, Республика порталы аша 14 эш көне тәшкил итә.

11. Хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң икенче көннән башлап исәпләнә башлый.

12. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә башкарыла.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны Палатада һәм күпфункцияле үзәктә бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Хезмәтне күрсәтү өчен гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, шулай ук Хезмәтне күрсәтүне туктатып тору яки хезмәтне күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар Палата тарафыннан түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документ текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерүләр һәм төзәтүләр булу;

2) документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган бозулар булу;

3)тапшырылган документлар яки белешмәләр (вәкаләтле зат муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документ; гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ) муниципаль хезмәт күрсәтү сорап мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдән чыккан булу;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны, билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон рәвештә бирү;

5 )Бердәм порталда яисә Республика порталында гариза формасындагы мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру;

7) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү керми торган җирле үзидарә органына яки оешмага тапшыру;

8) 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясы белән билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булуын тану шартларын үтәмәү.

14. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

15. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карарны Палата түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) Әлеге кодексның 32 статьясындагы 3 пункты нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә гражданнарга түләүсез бирү;

2) гражданнарның түбәндәге сәбәпләр нигезендә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве:

- Россия Федерациясе гражданлыгы бетү;

- Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китү;

- ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү, уллыкка алу кире кайтарылу, опекаяисә попечительлек туктатылу;

- ата-ананың берсенең (ата-ананың) законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында баланың (балаларның) вафат булуы;

- социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;

3) гражданнар тарафыннан аларны исемлекләрдән төшереп калдыру турында гаризалар бирелү;

4) җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында гражданнар җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса йә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килмәве , яки җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту очраклары һәм җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәүләре өчкә тигез булганда;

5) гражданнарны исемлекләргә кертүдә нигез булып торган документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килми торган һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен таныклый торган белешмәләрнең булуы ачыклану.

16. Хезмәтне күрсәтү өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре, мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) исәпкә алынып,

Хезмәтне күрсәтүдән баш тарту нигезләре Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

### Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

### Хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

18. Хезмәт күрсәтүне алуга гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан артык түгел.

19. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

### Мөрәҗәгать итүченең Хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы.

20. Күп функцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза тапшырылган көнне күп функцияле үзәкнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза бирү көне күрсәтелгән раслама бирелә.

21. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номерын һәм гариза бирү датасын күрсәтеп, гариза җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала.

22. Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны ике нөсхәдә тапшырган көнне, Органның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документлар күрсәтелгән бер нөсхәсе кире кайтарыла.

### Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә Хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) Хезмәт күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (бинага/биналардан керү/чыгу һәм алар чикләрендә уңайлы хәрәкәт итү);

2) Хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта, юл күрсәтүче этне кертергә рөхсәт итү.

25. Хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга инвалидларның керү мөмкинлеген һәм Регламентның 23 пунктының 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

26. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, КФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

27. Хезмәт күрсәтүнең файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре түбәндәгеләр:

документларны кабул итү алып барыла һәм тапшыра торган бинаның җәмәгать транспорты йөргән урыннарга якын урнашуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуда комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

28. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогын үтәү;

2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срокларын үтәү;

3) Палата хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән аралашуы гариза белән барлык кирәкле документларны биргәндә бер тапкыр башкарыла;

4.2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән бер тапкыр аралашу озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм портал, Республика порталы, терминал җайланмаларын кулланып бәяләргә хокуклы.

29. Хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә Республика порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә, яшәү урынына яки фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

31. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүне комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында алырга хокуклы.

32. Хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы күрсәткечләре турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, КФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтүгә карата башка таләпләр

33. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) Хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларның үтәлеше барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын Республика порталы аша бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм башкарылган (башкарылмаган) гамәлләргә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы, Республика порталы аша Палатаның, шулай ук андагы вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм башкарылган (башкарылмаган) гамәлләренә карата шикаять бирергә.

34.Гаризаны формалаштыру Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, теләсә нинди башка формада гариза бирү зарурлыгыннан башка гамәлгә ашырыла.

35. КФҮтә кабул итү өчен мөрәҗәгать итүчеләрне теркәү (алга таба - язылу) Республика порталы, КФҮ контакт телефоны аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә кайсы буш датага һәм вакытка кабул итү өчен язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә система тарафыннан соратып алына торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләге буенча);

кабул итү буенча теләгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән белешмәләр шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында аңа мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы аралыгын исәпләп чыгару өчен кирәк булган белешмәләр бирүдән тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

36. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге Регламентның 3 нче кушымтасында бирелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

а) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар ;

б) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

37. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар формалары турында мәгълүмат әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында бирелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

38. Хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) Хезмәтне күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;

3) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

Ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш

39. Хезмәт күрсәтүне алу өчен «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрергә кирәк:

1) «Күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратып

алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

2) «Язылышуны (аерылуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр»дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Рәсми мөрәҗәгать юридик зат хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Үлемне дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәте»нә Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

4) «Тууны дәүләт теркәве турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәте»нә Хезмәтләр күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

5) «Яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү хисабы турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы»соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

6) «Паспортның чынбарлыкка туры килүе турында белешмәләр»дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы»соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

7) «Фамилия-исем төркеменең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә ««Россия Социаль фонды»на җибәрелә. «Россия Социаль фонды» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра. Рәсми мөрәҗәгать индивидуаль эшкуар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

40. Хезмәт күрсәтүне алу өчен башка сервислар аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрү кирәк:

1) «Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры» сервисы я «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы аша,

мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, 1 эш көненнән артык булмаган вакытта гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы аша, мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3) «Бушлай җир кишәрлекләре бирелгән (тапшырылган) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар реестрыннан белешмәләр» дигән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать . Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать«Татарстан Республикасы җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы»на җибәрелә. «Татарстан Республикасы җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы» соратып алына торган мәгълүматны ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

41. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәтләр күрсәтүгә үзенең рәсми мөрәҗәгать статусы үзгәрү турында (документлар кабул итү турында; документлар комплектын карау турында; хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнары һәм гамәлләре турында санап үтелгән түбәндәге ысулларның берсе буенча хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
– Бердәм портал ярдәмендә;
– Республика порталы ярдәмендә;
– башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1 нче кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘРҺӘМ КЫСКАРТЫЛМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3. Федераль дәүләт мәгълүмат системасы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Зеленодольск муниципаль районы порталы» мәгълүмат системасы (https://zelenodolsk.tatarstan.ru/) – Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты;
5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты – Башкарма комитет;
6. Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ – Палата;
7. Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.

2 нче кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билге идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Исәпкә кую | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар | 1А |
| 2. | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 2А |

3 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-2А | Гариза | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 2. | 1А-2А | шәхесне таныклый торган документ (мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү шәхсән кабул иткәндә Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе гражданы паспортын я шәхесне таныклый торган башка документны күрсәтү юлы белән яисә 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән башкарылырга мөмкин) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 3. | 2А | Мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 4. | 1А-2А | 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге өлкән баланың белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасында уку фактын раслый торган документ | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар* | | | |
| 1. | 1А-2А | Ата-ана язылышкан булса йә язылышмаган, әмма бергә яши торган булса ата-ана паспорты (ата-ана язылышкан булса йә язылышмаган, әмма бергә яши торган очракта мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 2. | 1А-2А | Бала туу турында таныклык, чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе (бала тууы Россия | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Федерациясеннән читтә теркәлгән очракта мәҗбүри). | |
| 3. | 1А-2А | Чит дәүләт законнары нигезендә ун дүрт яшькә җиткән баланың паспорты (бала тууы Россия Федерациясеннән читтә теркәлгән очракта мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 4. | 1А-2А | Опека һәм попечительлек органының опекун яисә попечитель билгеләү турында акты (опека яисә попечительлек билгеләнгән очракта мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 5. | 1А-2А | Опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (опеканы яисә попечительлекне шартнамә буенча гамәлгә ашырганда мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 6. | 1А-2А | Язылышуны теркәү турында таныклык | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 7. | 1А-2А | Мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документы | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 8. | 1А-2А | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |
| 9. | 1А-2А | 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусын раслаучы документ (ата-аналарның берсе яки бердәнбер ата-ана хәрби хезмәткәр булса мәҗбүри) | Республика порталы, Башкарма комитет, Палата, КФҮ |

4 нче кушымта

**Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны |
|---|---|---|
| *Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-2А | Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пункты нигезендә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча элек кулланылган хокук |
| 2. | 1А-2А | гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә түбәндәгеләр сәбәпләр аркасында туры килмәве:<br>– Россия Федерациясе гражданлыгы бетү;<br>– Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китү;<br>– ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителү, уллыкка алу кире кайтарылу, опекаяисә попечительлек туктатылу;<br>– ата-ананың берсенең (ата-ананың) законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында баланың (балаларның) вафат булуы; |
| 3. | 1А-2А | Гражданнар тарафыннан аларны исемлекләрдән төшереп калдыру турында гаризалар бирү; |
| 4. | 1А-2А | җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында гражданнар җир кишәрлегенсайлап алудан өч мәртәбә баш тартса йә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килмәве , яки җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту очраклары һәм җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәүләре өчкә тигез булганда; |
| 5. | 1А-2А | гражданнарны исемлекләргә кертүдә нигез булып торган документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килми торган һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен таныклый торган белешмәләрнең булуы ачыклану |
| *Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
| 1. | 1А-2А | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документ текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерүләр һәм төзәтүләр булу |
| 2. | 1А-2А | Документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган бозулар булу; |
| 3. | 1А-2А | Тапшырылган документлар яисә белешмәләр муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдән чыккан булу (шәхесне таныклаучы документ; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, |

| | | |
|---|---|---|
| | | күрсәтелгән зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать ителгән очракта) |
| 4. | 1А-2А | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып электрон рәвештә тапшыру |
| 5. | 1А-2А | Республика порталында электрон формадагы гаризада юлларны тулысынча тутырмау |
| 6. | 1А-2А | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру |
| 7. | 1А-2А | 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законның 11 статьясы белән билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартлары үтәлмәүне ачыклау |
| 8. | 1А-2А | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылган |

5 нче кушымта

Форма

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

________________
________________ ________________
________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ ________________
Вәкил: _________________
________________
_________________
Вәкил белән элемтә өчен мәгълүмат:
_______________________________
________________ ________________

**Җир кишәрлеген түләүсез бирү максатыннан күп балалы гаиләне исәпкә алу турындагы карар**

______ елның___________________ _____номерлы

Татарстан Республикасы Җир кодексына ярашлы, ________________ № ________________ гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ________________ № _______________ карары нигезендә, мөрәҗәгать итүченең күп балалы гаиләсенә җир кишәрлеген түләүсез бирү максатыннан исәпкә алу турында карар кабул ителде: ________________.

Гаризаның уникаль номеры:

Чират номеры: ________________.

Өстәмә мәгълүмат: ________________.

Вазифаи зат (ФИАт.и) ________________________________

(органдагы вәкаләтле вазифаи затның имзасы)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

6 нчы кушымта

Форма

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

____________________________________
_________________________________
_________________________
Контакт мәгълүматлары:
________________ __________________
Вәкил: ____________________
__________________
____________________
Вәкил белән элемтә өчен мәгълүмат:
___________________________________
__________________ __________________

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

_____________________________

____________ № _______________ *(мөрәҗәгать итүченең гариза датасы һәм номеры)* гаризаны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге нигезләрдә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде *(кирәклесен сайларга):*

1. ___________________________________________________________________________
2. ___________________________________________________________________________

Баш тартуның сәбәпләрен аңлату: __________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: _______________________________________________
*(баш тартуның сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук булган очракта башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).*

Вазифаи зат (ФИАт.и) ____________________________________

(органдагы вәкаләтле вазифаи затның имзасы)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

7 нче кушымта

ФИАт.и.

Шәхесне таныклый торган документ:

(документ төре)

(сериясе, номеры)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Теркәлү адресы

Ышанычнамә буенча вәкил яки законлы вәкиле:

ФИАт.и.

Шәхесне таныклый торган документ:

(документ төре)

(сериясе, номеры)

(кем тарафыннан, кайчан бирелгән)

Вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары:

Теркәлү адресы

Элемтә өчен мәгълүмат:

1 тел. номеры ____________________

2 тел. номеры ____________________

электрон почта ____________________

Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую турында гариза

Сездән милеккә җир кишәрлеген бушлай бирүегезне сорыйм:

*(җир кишәрлегенең максатчан билгеләнешен күрсәтү: индивидуаль торак төзелеше,*

*шәхси ярдәмче хуҗалык , бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару)*

Гариза «__» ______ 20__ ел, «__» сәгать «___» минутта кабул ителде, һәм № _________ гаризалар кабул итүне исәпкә алу кенәгәсендә теркәлгән.

__________ _____________ ____________________________________________

*(дата)* *(имза)* *(гариза кабул иткән белгечнең Ф.И.Ат.и.)*

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәге ысул белән бирүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка;

☐ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә;

***Органда.***

Күп балалы гаилә әгъзаларының составы һәм имзалары:

| т/б | Күп балалы гаилә әгъзасы Ф.И.Ат.и. (тулысынча) | Туу датасы (саны/ае/елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорты, туу турында таныклыгы (серия, номер, кем тарафыннан бирелгән, бүлекчә коды) | 14 яшьтән һәм өлкәнрәк булган гаилә әгъзаларының имзалары |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

_______________ __________________ ( _________________)

*(дата)* *(имза)* *(Ф.И.Ат.и.)*

8 нче кушымта

Форма

(Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган бланкы)

______________________________
__________________________
________________
Контакт мәгълүматлары:
______________ ________________
Вәкиле: __________________
________________
Вәкил белән элемтә өчен мәгълүмат:
______________________________
________________ ________________

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

__________________________

__________ № _____________ *(мөрәҗәгать итүченең гариза датасы һәм номеры)* гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге нигезләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде *(кирәклесен сайларга):*

1. ______________________________________________________________
2. ___________________________________________________________

Баш тартуның сәбәпләрен аңлату: __________________________________________

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: __________________________________________
*(баш тартуның сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук булган очракта башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).*

Вазифаи зат (ФИАт.и) ______________________________

органның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

9 нчы кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә________________
____________________
_________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында җибәрелгән хата турында түбәндәгеләрне хәбәр итәм.
___________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

Язылган:__________________________________________________________
______________________________________________

Дөрес белешмәләр:____________________________________________
__________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны:

электрон документны E-mail адресына җибәрү юлы белән:_______;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь саклагычта почта аша ___________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл белешмәләрне үз эченә ала.

______________ _________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.Ат.и.)